Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 4-1**

Бәтке авылы 1 июнь 2017 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районының " Бәтке авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеген җирдән файдалану
һәм төзү кагыйдәләре турында

Территорияне тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тәртипле һәм нәтиҗәле җирдән файдалануны һәм төзелешне тәэмин итү максатларында, «Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Бәтке авыл җирлеге", 15.12.2016 Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы килешүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге Советы Карар итте:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының " Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авылы,Ленин урамы,4 йорт; Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт адреслары буенча урнашкан

махсус мәгълүмат стендларында  һәм Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында  һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне  үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы                Ф.М.Динмөхәммәтов